| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
07.08.2017

КАРАР
№ 898-п

Саба муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган «Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына исәпкә алу һәм күчерү» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентының якынча формасына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 09 июнендәге 1049/17 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 07 октябрендәге 1274-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына (Башкарма комитетының 2016 елның 26 гыйнварындагы 88-п номерлы, 2016 елның 10 июнендәге 715-п номерлы, 2017 елның 17 февралендәге 175-п номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 3.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең Оешмага чираттан тыш укырга хокукы булган очракта, мөрәҗәгать итүчегә «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУга ташламаны раслый торган документларны, шулай ук аларның күчермәләрен тапшырырга кирәк.»;

1.2. Административ регламентның 3.6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ташламалы категория балалары баланы бер оешмадан икенчесенә күчергәндә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка закон норматив хокукый актларда билгеләнгән ташламалардан файдалана.».

Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru бастырырга.

Җитәкче Р.М. Гасимов